Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар

2023 елның «27» феврале № 9

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендә 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 октябрендәгендәге 394-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендә 6 номерлы карарына (2022 елның 24 октябрендәге 23 нче номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырыла:

«- медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда булышлык күрсәтү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.Х.Гарифуллина